**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «3» августыннан

№ 25-193

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына һәм чик санына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча совет каршындагы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары структурасын камиллләштерү мәсьәләләре буенча эшче төркем утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтага нигезләнеп, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын һәм иң чик санын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структурасы һәм аның чик саны» дигән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 ноябреннән 2 нче кушымтаның 29 п. буенча хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карарына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның 08 апрелендәге 20-164 номерлы карары редакциясендә; 2022 елның 03 августыннан 25-193 номерлы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты структурасы

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Җитәкче | 1 |
| 2. | Җитәкченең беренче урынбасары (икътисад буенча) | 1 |
| 3. | Социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары | 1 |
| 4. | Инфраструктур үсеш буенча җитәкче урынбасары | 1 |
| 5. | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 1 |
| 6. | Мобилизация эшләре буенча җитәкче ярдәмчесе | 1 |
| | Мәгариф бүлеге | |
| 7. | Башлык | 1 |
| 8. | Башлык урынбасары | 1 |
| 9. | Баш белгеч | 1 |
| 10. | Баш белгеч (КДН белгече) | 1 |
| | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | |
| 11. | Башлык | 1 |
| 12. | Баш белгеч | 1 |
| 13. | Әйдәп баручы белгеч (ПДН белгече) | 1 |
| | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге | |
| 14. | Башлык | 1 |
| 15. | Баш белгеч | 1 |
| 16. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| 17. | Административ комиссия секретаре (хезмәткәр) | 1 |
| | Мәдәният бүлеге | |
| 18. | Башлык | 1 |
| 19. | Тәрҗемәче (хезмәткәр) | 1 |
| | Икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге | |
| 20. | башлыгы | 1 |
| 21. | Башлык урынбасары | 1 |
| 22. | Баш белгеч | 1 |
| 23. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | Опека һәм попечительлек бүлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 24. | Башлык | 1 |
| 25. | Баш белгеч | 1 |
| 26. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| Архив секторы | | |
| 27. | Мөдир | 1 |
| Мәгълүмат белән тәэмин итү һәм мәгълүмати иминлек секторы | | |
| 28. | Мөдир | 1 |
| ГХАТ секторы | | |
| 29. | Мөдир | 1 |
| Категориядән тыш | | |
| 30. | Автомобиль йөртүче | 4 |
| 31. | Җитәкче секретаре | 2 |